МИНИСТЕРСТВО
ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И
СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ
РЕСПУБЛИКИ
ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ
БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ
СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

12.10.2018 г.Казань № 938

ТР Юстиция министрлыгында 2018 елның 8 ноябрендә 4965 номеры белән теркәлде

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2015 елның 12 ноябрендәге 831 номерлы боерыгы белән расланган Гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Дәүләт хезмәтләрен күрсәтү эшен камилләштерү максатларында б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 12 ноябрендәге 831 номерлы боерыгы белән (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2016 ел, 4 февраль, № 61, 2017 ел, 11 декабрь, № 863, 2018 ел, 16 июль, № 561 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

2. Әлеге боерык рәсми рәвештә басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт,
халыкны эш белән тәэмин итү һәм
социаль яклау министрлыгының
2018 ел, 12 октябрь, №860 боерыгы
белән расланды

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 12 ноябрендәге 831 номерлы боерыгы белән расланган Гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

1 бүлектә:

1.3 пунктта 1.3.2 пунктчаның беренче абзацына «әлеге Регламентның» сүзләреннән соң «Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә» сүзләрен өстәргә;

1.5 пунктының җиденче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыны – дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең «Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2012 елның 22 декабрендәге 1376 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләренең 34 пункты нигезендә Татарстан Республикасының шәһәр яки муниципаль район (шәһәр округы) авыл җирлегендә булдырылган территориаль аерымланган структур бүлекчәсе (офисы).»;

2 бүлектә:

2.4 пунктта «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт хезмәте күрсәтүнең максималь мөмкин булган сроклары:

шәхсән мөрәҗәгать иткәндә 10 минуттан узарга тиеш түгел;

телефон аша шәхсән мөрәҗәгать иткәндә 10 минуттан артык булырга тиеш түгел;

язмача мөрәҗәгать иткәндә, шул исәптән электрон почта буенча, – мөрәҗәгатьне теркәгән вакыттан башлап 10 эш көненнән артык түгел. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору Россия Федерациясе законнарында каралмаган»;

3 бүлектә:

3.2 пункттагы икенче абзацны, 3.3 пунктның 3.3.1 пунктындагы алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла. Административ процедураларның

озынлыгы шәхсән мөрәҗәгать иткәндә консультацияли башлау вакытыннан башлап 10 минуттан һәм телефон аша сөйләшә башлаган вакыттан башлап 10 минуттан артып китәргә тиеш түгел.»;

3.3 пунктның 3.3.2 пунктчасындагы җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедуралар гариза алынганнан соң өч эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.»;

3.4 пунктның 3.4.1 пунктчасындагы дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедуралар 3.3.2 пунктчада каралган процедуралар тәмамланган вакыттан башлап биш эш көнендә гамәлгә ашырыла.»;

5 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның (оешманың), шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының (белгеченең) яисә дәүләт хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе

5.1. Мөрәҗәгать итүчеләр судка кадәр тәртиптә түбәндәгеләрнең гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерү хокукына ия:

территориаль орган белгечләренең – территориаль орган җитәкчесенә;

социаль хезмәт күрсәтүче оешма белгечләренең – социаль хезмәт күрсәтүче оешма җитәкчесенә.

Социаль хезмәт күрсәтүче оешма җитәкчесе карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр территориаль орган җитәкчесенә, территориаль орган җитәкчесе карарларына – Министрлыкка министрның тикшерүдә тотучы урынбасары исеменә, тикшерүдә тотучы министр урынбасары карарларына – министрга тапшырыла.

Министр урынбасары (министр) карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына белдерелергә мөмкин.

5.2. Мөрәҗәгать итүче, шул исәптән түбәндәге очракларда да, шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында гарызнамәне теркәү чоры бозылганда;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү чоры бозылганда;

3) мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы каралмаган документларны яки мәгълүматларны яисә гамәлләр башкаруны таләп иткәндә;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү буенча тапшырылырга тиешле, Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган документларны мөрәҗәгать итүчедән кабул итеп алудан баш тартканда;

5) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартканда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый

актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм бүтән норматив хокукый актларында баш тарту нигезләре каралмаган булса;

6) дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган түләү таләп ителгәндә;

7) дәүләт хезмәте күрсәтүче орган (оешма), дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи зат (белгеч) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә тапшырылган документларда үзләре тарафыннан җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тарткан очракта яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакыты бозылганда;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документларны бирү срогы яисә тәртибе бозылганда;

9) дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып торганда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм норматив хокукый актларында туктатып тору өчен нигезләр каралмаган булса;

10) дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралганнардан тыш, булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документларны яки мәгълүматны таләп иткәндә.

5.3. Дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның (оешманың), дәүләт хезмәте күрсәтүче органның (оешманың) вазыйфаи затының (белгеченең), дәүләт хезмәткәренең, дәүләт хезмәте күрсәтүче орган (оешма) җитәкчесе карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять язмача формада кәгазьдә яисә электрон формада тапшырыла.

Дәүләт хезмәтен алучылар тарафыннан шикаять почта белән, күпфункцияле үзәк аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып, Министрлыкның рәсми сайтыннан (http://mtsz.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан (http://uslugi.tatarstan.ru/), Дәүләт хезмәтләренең һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталыннан (http://www.gosuslugi.ru/) җибәрелергә, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә кабул итеп алынырга мөмкин.

5.4. Шикаятьне карау чоры – аны теркәүгә алганнан соңгы 15 эш көне эчендә. Дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның (оешманың), шулай ук дәүләт хезмәтен күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның (белгечнең) яки дәүләт хезмәткәренең мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән баш тартуын яисә җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуына шикаять белдерелгәндә яисә мондый төзәтмәләр кертүнең билгеләнгән вакыты бозылган очракта, – аны теркәүгә алганнан соңгы биш эш көне эчендә.

5.5. Шикаятьтә түбәндәгеләр булырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелә торган дәүләт хезмәте күрсәтүче органның (оешманың), дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның (белгечнең) яисә граждан хезмәткәренең исеме;

2) мөрәҗәгать итүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), яшәгән урыны турында белешмәләр, мөрәҗәгать итүче – юридик затның урнашкан урыны турында белешмәләр, шулай ук элемтә өчен телефон номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә мөмкин булган почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның (оешманың), дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы (оешмадагы) вазыйфаи затның (белгечнең) яки дәүләт хезмәткәренең шикаять белдерелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында мәгълүматлар;

4) мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтүче органның (оешманың), дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы (оешмадагы) вазыйфаи затның (белгечнең) яисә дәүләт хезмәткәренең карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) белән ризалашмавын нигезләүче дәлилләр. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөрәҗәгать итүченең дәлилләрен раслый торган документлар (булган очракта) яки аларның күчермәләре тапшырылырга мөмкин.

5.6. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында алуы каралмаган түләүләрне кайтарып бирү рәвешендә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

Карарны кабул иткән көннән соң бер көн узганчы мөрәҗәгать итүчегә язмача яисә гражданин ихтыяры буенча электрон рәвештә шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында нигезләнгән хат җибәрелә.

5.7. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта җавапта мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәтен күрсәткәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән юк итү максатларында дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган (оешма) тарафыннан гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм дәүләт хезмәтен алу максатларында алга таба мөрәҗәгать итүче эшләргә тиешле гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.8. Шикаять канәгатьләндерергә тиешле түгел дип танылган очракта мөрәҗәгать итүчегә җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында нигезле аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять белдерү тәртибе турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.9. Шикаятьне карау барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять кылу билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карау вәкаләте бирелгән вазыйфаи зат булган материалларны прокуратура органнарына кичекмәстән җибәрә.».

Гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 2 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**Гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең блок-схемасы**

```
                              Мөрәҗәгать итүче
                                     |
                                    \/
  Территориаль органга яки социаль хезмәт күрсәтүче оешмага дәүләт хезмәте күрсәтү
                              өчен мөрәҗәгать итү
            |                                        |
           \/                                       \/
     Телдән (шәхсән яки                    Язмача, шул исәптән электрон
        Телефон аша)                          документ формасында
            |                                        |
           \/                                       \/
      Дәүләт хезмәтен                     Гаризаны теркәү һәм дәүләт хезмәте
          күрсәтү                        күрсәтүдән баш тарту нигезләре булу-
                                                 булмавын тикшерү

            |                                        |
           \/                                       \/
  Территориаль орган белгече                 Мәгълүмат хаты проектын әзерләү
  яки социаль хезмәт күрсәтүче              һәм имза кую өчен территориаль орган
  оешма белгече дәүләт хезмәте             җитәкчесенә яки социаль хезмәт күрсәтүче
  күрсәтүне теркәү журналында                     оешма җитәкчесенә җибәрү
  дәүләт хезмәтен күрсәтү турында
          язуны терки

                                                     |
                                                     |

                                                    \/

                                        Мәгълүмат хаты проектын имзалау һәм
                                   территориаль орган яки социаль хезмәт күрсәтүче
                                             оешма белгеченә җибәрү
                                                     |
                                                    \/
                                         Мөрәҗәгать итүчегә мәгълүмат хаты җибәрү
```

Гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына белешмәлек кушымтада:

1.4 пунктта 4 һәм 8 юлларны төшереп калдырырга;

1.6 пунктта:

9 юлда дүртенче графаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«422110, Кукмара ш., Эшчеләр тыкрыгы ур., 4, E-mail: reabkuk@mail.ru»;

11 юлны төшереп калдырырга;